**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Об отмене карантина, установленного на территории села Сахаровка Алексеевского района Республики Татарстан и на отдельной территории Актанышского района Республики Татарстан в связи с их неблагополучием по заболеванию бешенством животных**

В связи с истечением двух месяцев со дня последнего случая заболевания животных бешенством и выполнением противоэпизоотических и профилактических мероприятий, в соответствии со статьей $3^1$ Закона Российской Федерации от 14 мая 1993 года № 4979-I «О ветеринарии» **постановляю:**

1. Отменить карантин, установленный в связи с неблагополучием по заболеванию бешенством животных:

а) на территории села Сахаровка Алексеевского района Республики Татарстан;

б) на территории, используемой обществом с ограниченной ответственностью Агрофирмой «Актаныш» (подразделение «Тыннамасово») для содержания крупного рогатого скота, у села Казкеево Актанышского района Республики Татарстан.

2. Признать утратившим силу Указ Президента Республики Татарстан от 18 марта 2020 года № УП-176 «Об установлении карантина на территории села Сахаровка Алексеевского района Республики Татарстан и на отдельной территории Актанышского района Республики Татарстан в связи с их неблагополучием по заболеванию бешенством животных».

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казань, Кремль
19 мая 2020 года
№ УП-295

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Алексеевск районының Сахаровка авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасы Актаныш районының аерым территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерү турында**

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Терлекләр котыру авырулы булганга, иминлексезлек сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:

а) Татарстан Республикасы Алексеевск районының Сахаровка авылы территориясендә;

б) Татарстан Республикасы Актаныш районының Көзкәй авылы янындагы «Актаныш» агрофирмасы җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең («Тыңламас» бүлекчәсе) мөгезле эре терлек асрау өчен файдаланылучы территориясендә.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Алексеевск районының Сахаровка авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасы Актаныш районының аерым территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2020 елның 18 мартындагы ПУ-176 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ — Татарстан Республикасы Президенты Аппараты / Аппарат Президента Республики Татарстан

Казан, Кремль
2020 ел, 19 май
№ ПУ-295